КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 ноябрь

г.Казань

№ 1048

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына (алга таба – Ярдәмче программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең егерме өченче абзацында «алар арасында субсидияләр бүлүне» сүзләрен «алар арасында башка бюджетара трансфертлар бүлүне» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең унсигезенче абзацында «субсидияләр исәбеннән» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар исәбеннән» сүзләренә алыштырырга;

Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаның «Яшь гаиләләргә бирелгән социаль түләүләрне башкару өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр күчерү» юлында «субсидияләр күчерү» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар күчерү» сүзләренә алыштырырга;

Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымтада:

15 нче пунктның «з» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«з) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасын индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның күчермәсен.»;

28 нче пунктның икенче абзацында «субсидияләрне этаплап бүлү» сүзләрен «башка бюджетара трансфертларны этаплап бүлү» сүзләренә алыштырырга;

32 нче пунктта «субсидияләр бирүгә» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар бирүгә» сүзләренә алыштырырга;

34 нче пунктның «б» пунктчасында «субсидияләрдән файдалану» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлардан файдалану» сүзләренә алыштырырга;

Ярдәмче программага теркәлгән 5 нче кушымтаның 10 нчы пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) гаиләнең һәр балигъ булган әгъзасын индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның күчермәсен;».

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче карары редакциясендә)

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы кысаларында Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм аларны сарыф итү максатларын, тәртибен һәм шартларын, яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр (алга таба – 1 нче ярдәмче программа, социаль түләүләр) бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнарын һәм шәһәр округларын сайлап алу критерийларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) чикләрендә бирелә.

3. Татарстан Республикасы бюджетының башка бюджетара трансфертлар бирү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасының яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр акчасы исәбеннән һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Министрлык тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге критерийларга җавап бирә торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

муниципаль берәмлектә планлаштырыла торган елда социаль түләү алырга

теләк белдергән муниципаль программада катнашучы, 1 нче ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләү бирү шартларына туры килүче яшь гаиләләр булу;

планлаштырыла торган елда социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлеге булу.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

муниципаль берәмлектәге җирле үзидарә органының тиешле чорга яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча муниципаль программаны раслау турында муниципаль хокукый акты булу һәм анда бу Тәртипнең 14 нче пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече бирелү;

муниципаль берәмлек бюджетында муниципаль берәмлекнең Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган бюджетара трансфертларны үз эченә алган чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре (бюджетның җыелма бюджет исемлеге) булу;

бу Тәртипнең 10 нчы пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү төзү.

7. Башка бюджетара трансфертларны бүлү максатларында, муниципаль берәмлектәге җирле үзидарә органының вәкаләтле органы (алга таба – вәкаләтле орган) Министрлык тарафыннан билгеләгән вакытларда һәм форма буенча Министрлыкка планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга теләк белдергән гаиләләр исемлеген кертә.

8. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында бүлү, муниципаль берәмлектә планлаштырыла торган елда социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлегенә кертелгән яшь гаиләләр санын исәпкә алып, муниципаль берәмлектә һәркем өчен мөмкин булган торак булудан һәм 1 нче ярдәмче программа шартлары нигезендә яшь гаиләгә бирелә торган социаль түләү күләменнән чыгып, түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$\mathrm{OTMO_i} = \left(\text{Ц}^{\mathrm{i}}_{\text{кв.м}} \times \text{кв.м}_{\mathrm{i}}\mathrm{MC_1}\right) + \left(\text{Ц}^{\mathrm{i}}_{\text{кв.м}} \times \text{кв.м}_{\mathrm{i}}\mathrm{MC_2}\right) + \left(\text{Ц}^{\mathrm{i}}_{\text{кв.м}} \times \text{кв.м}_{\mathrm{i}}\mathrm{MC_n}\right),$$

монда:

i – муниципаль берәмлекнең исеме;

$\mathrm{OTMO_i}$ – i-муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансферт күләме;

$\text{Ц}^{\mathrm{i}}_{\text{кв.м}}$ – i-муниципаль берәмлегендә квадрат метр бәясе;

$\text{кв.м}_{\mathrm{i}}\mathrm{MC_n}$ – i-муниципаль берәмлегендә түләү өчен n-яшь гаиләгә социаль түләү бирелә торган квадрат метрлар саны (нумерациясе планлаштырыла торган елда социаль түләү алуга дәгъва итүчеләр исемлегенә кергән i-муниципаль берәмлегенең гаиләләр исемлеге нигезендә бирелә).

9. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүлү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм муниципаль берәмлек арасында Министрлык белән расланган форма буенча төзелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

а) башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

б) башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече мәгънәләре;

в) башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

г) башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченә ирешү;

д) башка бюджетара трансфертлардан файдаланучының башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәвенең зыяннары;

е) башка бюджетара трансфертлардан файдаланучы тарафыннан килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

ж) килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлар Федераль казначылыкның муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасы белән операцияләрне исәпкә алу өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә ачылган территориаль органы счетына килешү белән билгеләнә торган вакытларда билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

12. Башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлек бюджетына күчерү муниципаль берәмлекләрдән агымдагы кварталга акча бүлеп бирү өчен Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча заявкалар (алга таба – заявка) керүгә карап гамәлгә ашырыла

13. Муниципаль берәмлек тарафыннан акча бүлеп бирүгә заявка килешү белән билгеләнгән вакытларда кертелмәгән очракта, файдаланылмаган акча Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлекләр арасында алга таба яңадан бүленә.

14. Социаль түләүләр алуга бәйле рәвештә, торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр саны башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече булып тора.

15. Нәтиҗәлелек (нәтиҗә) күрсәткече мәгънәсенә ирешүгә бәя бирү Министрлык тарафыннан күрсәткечнең факттагы һәм пландагы мәгънәсен чагыштырып гамәлгә ашырыла.

16. Әгәр дә муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферт бирелгән елның 31 декабренә бу Тәртипнең 10 нчы пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә килешү белән күздә тотылган йөкләмәләр бозылган булса һәм әлеге бозулар башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соң килә торган елда килешү нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече мәгънәсенә ирешү турында хисап тапшыруның беренче көненә кадәрге

вакытка бетерелмәгән булса, башка бюджетара трансферт бирелгән елдан соң килә торган елның 1 июненә кадәр җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{\text{кире кайтару}} = \left(V_{\text{башка бюджетара трансферт}} \times k\right) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{\text{башка бюджетара трансферт}}$ – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

k – башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

17. Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләгәндә, хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләмендә ($V_{\text{башка бюджетара трансферт}}$) агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше күләме исәпкә алынмый.

Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$k = \text{SUM}\, D,$$

монда:

D – башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс.

Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициентын исәпләгәндә, индексның башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган уңай күрсәткечләр генә кулланыла.

18. Башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс түбәндәгечә билгеләнә:

а) фактта ирешелгән мәгънәнең зур мәгънәсе башка бюджетара трансферттан файдалануның зур нәтиҗәлелеген чагылдыра торган башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре өчен – түбәндәге формула буенча:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап көненә башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченең план буенча мәгънәсе;

б) фактта ирешелгән мәгънәнең зур мәгънәсе башка бюджетара трансферттан файдалануның аз нәтиҗәлелеген чагылдыра торган башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече өчен – түбәндәге формула буенча:

$$D = 1 - \frac{S}{T}.$$

19. Министрлыкка тапшырыла торган хисаплылыкның дөреслеге өчен җавап бирү вәкаләтле органга йөкләнә.

20. Башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчасы Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтарылырга тиеш.

21. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган һәм ул максатчан файдаланылмаган очракта, башка бюджетара трансферт Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә түләтелергә тиеш.

22. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган, шул исәптән башка бюджетара трансфертлар акчасы бу Тәртипнең 16 нчы пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнары белән күздә тотылган бюджетка кагылышлы мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

23. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашыра.